Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

13 январь 2016 ел № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең коммуналь инфраструктура - су белән тәэмин итү объектларына карата концессион килешү төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 51 статьясы, «концессион килешүләр турында» 21.07.2005 ел, № 115-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең су белән тәэмин итү объектларына карата концессион килешү төзү хокукына ачык конкурс үткәрергә.
2. Конкурсны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Д.Ә.Газизовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә. Газизов.